## ВЕЛИЕВ А. XXI ГАСЫР БАШЫ АЗӘРБАЙҖАН ТЕАТРЫ

А. Велиевның «XXI гасыр башы Азәрбайҗан театры» монографиясе Азәрбайҗан милли театрының СССР таркалу һәм республиканың бәйсезлеген торгызу чорындагы проблемаларын өйрәнеп тикшерүгә багышланган. Китап авторның күпьеллык тикшеренүләренә нигезләп язылган һәм ул басманың темасына тулысынча тәңгәл килә.

Әлеге хезмәттә Азәрбайҗан театр сәнгатенең бөтенлеген тәшкил иткән һәртөрле оештыру юнәлешләре, шулай ук аның бәйсез, мөстәкыйль формадагы үсеше тәкъдим ителә.

Авторның максаты – бүгенге шартларда Азәрбайҗан театрын торгызу буенча потенциаль мөмкинлекләрне, аның хокукый, икътисади нигезләрен, матди-техник үзенчәлекләрен ачыклау. А. Велиев аны милли мәдәниятне торгызу сәясәте контекстыннан чыгып, билгеләнгән стратегик принципларга һәм нәзари үрнәкләргә (модельләргә) таянып тормышка ашыра.

Автор үзенең монографиясендә бүгенге заман театры үсеше процессларын оптимальләштерүче нәзари үрнәкләр (модельләр) булдыруны бурыч итеп куя.

Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, авторның эзләнү-тикшеренүләре югары бәяләүгә лаек нәтиҗәләр бирә.

А. Велиев, бөтендөнья театры концептуаль үрнәкләреннән (модельләреннән) файдаланып, Азәрбайҗан театрын һәрьяклап прагматик призма аша бәяли. Азәрбайҗанда театр эшчәнлегенең яңа шартлардагы үсешен билгеләүче иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм хокукый реалияләргә зур игътибар бирә. Театр эшчәнлегенең идеологик һәм административ принципларына чагыштырма анализ ясап, дөньякүләм театр сәнгатенең заманча модельләренә аерым туктала, «театраль киңлек» төшенчәсенең мәгънәсен ача.

Үз темасы буенча чыганаклар базасының байлыгына карамастан, монография авторы тарихи-мәдәни даирәнең, сәнгать белеменең һәм борынгыдан (Борынгы грек театры, Борынгы Рим театры һ.б.) сакланып калган рухи мирасның аерым өлкәләренә дә мөрәҗәгать итә, тынгысыз эзләнүләре һәм практик эшчәнлеге нәтиҗәсендә яңа материаллар таба (мәсәлән, Көнбатыш Европада һәм АКШтагы театраль процесслар хакында). Алар китапның фәнни әһәмиятен күтәрәләр.

Сүз дә юк, бүгенге дөньяның югары технологияләре, теләсә нинди ераклыкка мәгълүмат тапшыруның зур тизлеге кешеләрне тагын да катлаулырак, техник яктан заманча җиһазландырылган күңел ачу чараларына ныграк җәлеп итә. Шуңа күрә автор китабында Азәрбайҗанның хәзерге милли театр оештыру процессындагы матди-техник үзенчәлекләргә аерым бүлек багышлый.

Китап, үз халкының мәдәнияте белән тирәнтен кызыксынып тикшеренүче – театр белгеченә хас булганча, матур тел белән,

мавыктыргыч, тәэсирле итеп, милли төсмерләргә баетылып язылган. Басмада күптөрле, шул ук вакытта махсус сайланган, зур кыйммәткә ия истәлекле иллюстрацияләр урын алган.

Китапның кушымтасына «Театр һәм театр эшчәнлеге турында» Азәрбайҗан Республикасы Законы, «Азәрбайҗан театр сәнгате үсеше турында» Азәрбайҗан Республикасы Президенты боерыгы, ««2009–2019 елларда Азәрбайҗан театры» Дәүләт программасын раслау турында» Азәрбайҗан Республикасы Президенты боерыгы, «“2009–2019 елларда Азәрбайҗан театры” Дәүләт программасы» кебек дәүләткүләм документларны өстәп, автор Азәрбайҗанда театр сәнгатенә бүгенге хакимиятнең мөнәсәбәтен ассызыклый.

Кешеләр тормышына вакыт китергән котылгысыз үзгәрешләр сәнгатьнең бу төре өчен куркыныч янамый. Театр дөньясы – рухи интеллектуаль кеше өчен иң мөһиме. Автор шушы хакыйкатьне аңлап кына калмый, әлеге төшенчәне монографиясендә тагын да тирәнрәк чагылдыруга ирешә.

***Шаһиев Рәфкать Шириаздан улы,***
*филология фәннәре кандидаты.*
*Әлмәт шәһәре*